ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**27.07.2023 ел** **№ 993**

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын урнашкан территорияләрнең чикләрен билгеләү буенча махсус комиссия төзү турында» 2023 елның 25 октябрендәге 893 номерлы карары үз көчен югалткан дип тану хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган территорияләргә якын урнашкан чикләрне җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 23 декабрендәге 2220 номерлы карары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, алкогольле һәм спиртлы продукция әйләнешен җайга салу, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән кайбер оешмалар һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү буенча норматив-хокукый актлар кабул итүгә бәйле куркынычларны бәяләү өлкәсендә тиешле чаралар эшләү максатларында, Биектау муниципаль районы Уставына таянып, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын урнашкан территорияләрнең чикләрен билгеләү буенча махсус комиссия төзү турында» 2021 елның 25 октябрендәге 893 номерлы карары үз көчен югалткан дип таныырга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин

.